Раслады:
“Ямаширмә “Йолдыз” балалар
бакчасы мөдире
_____ Л.М.Гыймадиева
Педагогик утырыш № 4
“20” 05 2024 ел.

# 2023- 2024 нче уку елына Биектау муниципаль районы «Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасының җәйге сәламәтләнедерү чорына эш планы

Раслады:
"Ямаширмә "Йолдыз" балалар
бакчасы мөдире
_______ Л.М.Гыймадиева
Педагогик утырыш № 4
"20" 05 2024 ел.

# 2023- 2024 нче уку елына Биектау муниципаль районы «Ямаширмә "Йолдыз" балалар бакчасының җәйге сәламәтләнедерү чорына эш планы

Раслады:
“Ямаширмә “Йолдыз” балалар
бакчасы мөдире
_____ Л.М.Гыймадиева
Педагогик утырыш № ___
“___” _________ 20 ___ ел.

# 2023- 2024 нче уку елына Биектау муниципаль районы «Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасының җәйге сәламәтләнедерү чорына эш планы

**Максат:** мәгариф оешмасының ФББП сына күчү: идарә итү карарлары һәм методик адымнар. ФББП нигезендә балалар бакчасының төп гомуми белем бирү программасын кертү өчен оештыру-методик шартлар булдыру

**Бурычлар:**

1) баланы һәм аның ата-аналарын (законлы вәкилләрен), яшәү урыны һәм төбәгенә карамастан, мәктәпкәчә белем бирүнең тигез, сыйфатлы шартларын тәэмин итүче, туганнан алып гомуми белем бирү оешмасына керүгә кадәр балаларны сәламәтләндерү, тәрбияләү һәм үстерүнең бердәм белем бирү киңлеген булдыру;

2) мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыруга методик ярдәм күрсәтүне тәэмин итү;

– мәктәпкәчә белем бирүнең федераль белем бирү программасын (алга таба-ФББП) куллану мәсьәләләрендә педагогик хезмәткәрләрнең компетенцияләрен арттыру;

ФББП кертүнең нәтиҗәлелеген контрольдә тотуны тәэмин итү;

-үсеш алучы предмет-тирәлек мохитне модернизацияләү, сыйфатлы һәм уңайлы белем бирү һәм иҗади мохитне үстерү;

-мәгариф эшчәнлеген матди-техник тәэмин итүне анализлау, заманча үсеш алучы предмет-пространственный мохит булдыру өлешендә мониторинг оештыру.

3) педагогларның игътибарын мәктәпкәчә яшьтәге балаларны милли, гаилә кыйммәтләрен исәпкә алып, тәрбияләү һәм сөйләм компетентлыгын формалаштыру ысулларына һәм чараларына юнәлтү.

<table>
<tr><th>Айлар</th><th>Атналыкның темасы</th><th>Көннәр темасы</th></tr>
<tr><td rowspan="3">Июнь</td><td colspan="2">1 нче атна</td></tr>
<tr><td>« Бала кешелек доньясында»</td><td>Балаларны яклау көне (Күмәк уеннаруйнату )<br>Экологлар көне<br>Экологлар белән очрашу оештыру<br>Рус теле көне, бөек рус шагыйре Александр Сергеевич Пушкинның туган көне (1799-1837)<br>(Икенче кечкенәләр төркемендә “Роберт Миңнуллин –балалар шигырьләренең атасы.”<br>Кечкенәләр төркеме “Авыл китапханәсенә экскурция”)<br>Агачларны яклау көне<br>(Икенче кечкенәләр төркеме-Зәкәрия Әхмәров буенча “Агачлар да авырый” исемле мультфильмен карау.<br>Кечкенәләр төркеме-<br>Балалар утырткан агачларга сулар сибү, төпләрен йомшарту)<br>«Әкият» көне<br>(Саф һавада әкияти спорт бәйрәме)</td></tr>
<tr><td colspan="2">2 нче атна</td></tr>
</table>

| | | |
|---|---|---|
| | **«Күп белүчеләр атнасы»** | **Әкиятләр көне.**<br>(Татар –рус халык әкиятләре белән таныштыру)<br>**Рәсәй көне** ( Икенче кечкенәләр төркемендә –“Без яшибез дуслык илендә” презентация карау.<br>Кечкенәләр төркемендә-әңгәмә , халык уеннары уйна , җырлар җырлау, презентация карау).<br>**Уенчыклар көне**<br>( Әңгәмә, рольле уеннар)<br>**Музыка көне**<br>(Уен мәйданчыгында җырлы- биюле күмәк уеннар.Төрле уен коралларында музыкалар тыңлау)<br>**Кыр чәчәкләре көне**<br>(Кыр чәчәкләре турында әңгәмә. Кыр чәчәкләреннән ясалган букет конкурсы. Ике группа арасында ярыш) |
| | **Знче атна** | |
| | **Капма-каршылыклар атнасы** | **Капма- каршылыклар көне**<br>(Балалар ак футболка, кара шортылардан киләләр. Тирә –юньдәге капма-каршы предметларны эзлиләр)<br>**Кояш көне**<br>( Г.Тукай ”Яңгыр илә кояш”, “Ай һәм кояш” мультфильмнәрен карау.)<br>**Су көне**<br>(Суның әһәмияте турында әңгәмә .<br>Икенче кечкенәләр төркемендә Г.Тукайның “Су анасы” мультфильмен карау. Кечкенәләр төркемендә “Гарифә чишмә”сенә экскурция.)<br>**Юхиди көне**<br>(Икече кечкенәләр төркемендә юлбилгеләре белән таныштыру.<br>Кечкенәләр төркемендә –юл билгеләре белән танышып машина паркына экскурсия ) |
| | **4 атна** | |
| | **« Спорт һәм сәламәтлек атнасы»** | **Дару үләннәре көне**<br>(Икенче кечкенәләр төркеме –Дару үләннәреннән гербарийга үлән җыю.<br>Кечкенәләр төркеме –Дару үләннәре белән танышу өчен болынлыкка экскурция)<br>**Сәламәтлек көне**<br>(Бакча күләм чыныктыру чаралары уздыру; ялан аяк чыкта йөрү, сәләмәтлек сукмагында эшчәнлек алып бару)<br>**Спорт көне**<br>**(**Уен участогында бакчакүләм күңелле эстафеталар уздыру)<br>**Туплар көне**<br>(Икенче кечкенәләр төркемендә туп белән уеннар оештыру)<br>Кечкенәләр төркемендә –стадионда футбол уйнауны оештыру) |

| | | |
|---|---|---|
| | | **Атлар көне**<br>**(**Икенче кечкенәләр төркемендә атлар турында ”Лошадка “ исемле мультфильмне карау.<br>Кечкенәләр төркемендә-атлар тора торган җиргә экскурсия) |
| | **1 атна** | |
| **Июль** | **“Үзең дә өйрән - башкаларны да өйрәт”** | **«Ком» көне**<br>(“Участокта иң яхшы кул эше” конкурсы)<br>**“Җәйге сәламәтлек көне”**<br>**Айболит көне**<br>(Чыныктыру чаралары уздыру)<br>**Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көне** (Клоуннар белән уен мәйданчыгында уен оештыру. Шаян шигырьләр уку, шаян җырлар җырлау, такмаклар такмазалар әйтешү)<br>**Кызыл бантиклар көне**<br>( Кызыл бантиклар тагып килү)<br><br>**Кызыксынулар көне**<br>(Экспериментлар уздыру) |
| | **2 нче атна** | |
| | **«Күңел ачу атнасы»** | **Салават күпере көне**<br>(Салават купере журналы белән таныштыру. Эксперимент “Салават күпере” ясау<br>**Спорт көне**<br>(Күңелле эстафеталар оештыру)<br>**Уеннар көне**<br>(Уен мәйданчыгында рольле уеннар оештыру)<br>**Җиләк көне**<br>( Икенче кечкенәләр төркемендә-“Җиләк җыям, как коям” уенын оештыру.<br>Кечкенәләр төркемендә-җиләкле тау итәгенә экскурция оештыру<br>**Балыкчылар көне**<br>( Икенче кечкенәләр төркеме -балыкчылар турында әңгәмә оештыру. “Балык тотам” уенын оештыру<br>Кечкенәләр төркеме –Шушма буендагы балыкчылар янына экскурция оештыру |
| | **3 атна** | |
| | **“Әкияттә кунакта”** | **Әкият геройларында кунакта**<br>Әкият геройлары белән бергә уен участогында уеннар оештыру |
| | | **Әкият карау** |

| | | |
|---|---|---|
| | | (Икенче кечкенәләр –“Теремкәй” әкиятен карау<br>Кечкенәләр төркеме - “Пряничный домик” әкиятен карау.)<br>**« Нептун көне»** |
| | | **Әкият геройлары белән курчак театры күрсәтү**(сотрудниклар белән бергә) |
| | | **«Асфальтта рәсем ясау» көне** |
| | **4 атна** | |
| | **“Эксперимен тлар атнасы”** | **Фокусчылар көне**<br>**(**Нәни фокусчылар кичәсе уздыру) |
| | | **Җиләк- җимешләрнең үсешен тикшерү көне**<br>(Участокта тәҗрибәләр уздыру) |
| | | **Бакчадагы чәчәкләрнең үсешен тикшерү көне**<br>( Икенче кечкенәләр төркемендә  бакча һәм болын чәчәкләрен төрләрен өйрәнү<br>Кечкенәләр төркемендә –үзләре утырткан чәчәкләрнең үсешен тикшерү орлыкларын җыю) |
| | | **Хәрби-диңгез флоты көне**<br>(Уен майданчыгында  уеннар оештыру) |
| **Август** | **1атна** | |
| | **«Табигать белән<br>икәүдән икәү генә»** | **Һава-десант гаскәрләре көне Тынычлык көне**<br>(Матур әдәбият әсәрләре уку. Тынычлык символикасы – күгәрчен (әңгәмә уздыру,  күгәрченне кулга тотып килү)<br>**Җәнлекләр көне.**<br>(Җәнлекләр турында табышмаклар әйтешү, әкиятләр уку)<br>**Кошлар көне.**<br>(“Очты, очты, каргалар очты” уенын оештыру)<br>**Яшелчә, җиләк –җимешләр көне.**<br>(Тәҗрибә участогында күзәтүләр оештыру)<br>**«Светофор» көне**<br>(“Умники и умницы” викторинасын оештыру) |
| | **2 атна** | |
| | **«Танып белү атналыгы »** | **Кәгазь көне.**<br>(Китап килеп чыгышы турында презентация карау)<br>**Металл көне.**<br>(Магнит белән тәҗрибә уздыру)<br>**Төрле төсләр көне** |

| | | |
|---|---|---|
| | | (Кызыл, сары, яшел бантиклар тагып килү)<br>**Светофор көне**<br>(Балалар иминлеген саклау өчен  чаралар уздыру)<br>**"Без көчле, кыю, батыр"**<br>(Батырлык турында матур әдәбият уку) |
| | **3 нче атна** | |
| | **«Яраткан уеннар»** | **Өстәл уеннары көне**<br>(Домино,пазлы, шашка уеннарын оештыру)<br>**Туплы уеннар көне**<br>(Уен майданчыгында футбол уеннары оештыру)<br>**Йомшак уенчыклар көне**<br>(Икенче кечкенәләр төркемендә йомшак уенчыклар турыда мульфильмнар карау<br>Кечкенәләр төркемедә йомшак уенчыклар белән  биюле уеннар оештыру)<br>**Россия Федерациясе Дәүләт флагы көне**<br>**Уен һәм көлке көне**<br>(Уен майданчыгында әкият геройлары белән уеннар оештыру) |
| | **4 атна** | |
| | **«Кызыклы эшләр»** | **Сабын куыклары көне**<br>(Сабын куыклары очыртуны оештыру)<br>**Татарстан флагы көне**<br>(Татарстан флагы төсләрендә киенеп килүне оештыру)<br>**Ноталар көне**<br>(Балалар җырларын бергәләп җырлауны оештыру)<br>**Чисталык көне**<br>(Территорияне чистарту эшләрен оештыру)<br>**Татарстан  Республикасы көне**<br>(Җәйге чорда туган балаларны котлап  уен майданчыгында уеннар оештыру) |

## Җәйге чорга эш планына кушымта

**Балаларны яклау көненә уеннар**

### Аю-бүре

Бу күмәк уен җәй көне тышта, җае туры килгәндә, әрәмәлек буйларында уйнала.

Балаларның берсе аю яки бүре булып берәр җирдә посып тора. Башкалары урманга «җиләк җыярга» китәләр. Берәү аларга каршы очрап сораша:

— Дуслар, кая барасыз?

— Кара урманга барабыз.

— Кара урманда нишлисез?

— Кура җиләк җыябыз.

— Җилә к белән нишлисез?

— Җиләктән как коябыз.

— Бүре килсә нишлисез?

— Урман буйлап чабабыз.

Аннан соң барысы да күмәкләп җырлыйлар:

*Җиләк җыям, как коям,*
*Дәү әнигә бүләккә;*
*Монда җиләк күп икән,*
*Аю-бүре юк икән.*

Бүре яшеренгән җиреннән сикереп чыга да аларны куа башлый. Кемне тотса, шул бүре була.

Уен йөгереклек һәм җитезлек сәләтен үстерүгә ярдәм итә.

### Кап та коп

Берничә бала бер түгәрәк булып утыралар, бер-берсенең баш бармакларын учлаган килеш, йодрыкларын йодрык өстенә куеп, кулларын бергәләп күтәреп-төшереп шуны әйтәләр:

*Без-без, без идек,*
*Без унике кыз идек;*
*Базга төштек бал ашадык,*
*Келәткә кердек май ашадык;*
*Өйгә мендек өйрә эчтек,*
*Коега төштек су эчтек;*
*Бер тактага тезелдек,*
*Таң атканчы юк булдык,*
*Кап та коп,*
*Авызыңны ач та йом! —*

диләр дә барысы да берьюлы авызларын йомалар.

Моннан соң уенчылар берсе дә авызын ачмаска, көлмәскә, сөйләшмәскә тиеш.

Алар бер-берсен көлдерү өчен төрлечә кыланалар, күз-йөз белән төрлечә ымнар ясыйлар. Кем иң элек авызын ачса, йә көлеп җибәрсә, аннан:

— Күктән кемнең өе башына төштең? — дип сорыйлар.

Ул берәр таны ш өйне атый. Шуннан соң ул өйдә ире, хатыны, балалары белән ничә кеше булса, көлүченең үзен дә кушып, һәрбер уйнаучы бу көлгән кешенең кулына йә маңгаена шулар санынча чиртеп ала. Уен тагын яңадан башлана.

## Җиз бүкән

Йөгереклекне, җитезлекне үстерү өчен бу уен күбрәк малайлар арасында җәй көне тышта уйнала.

Балалар бер түгәрәк булып, җирдә «җиз бүкән» булып, чүгеп утыралар. Һәрберсенең артында бер малай басып саклап тора. Арада бер малай бүкәнсез калдырылган була. Ул арттан килә дә «сакчы» белән сүз башлый:

— Җиз бүкән, җиз бүкән сатлык микән?

— Җиз бүкән сатлык икән.

— Күпме хак алыр икән?

— Хак ярым хак, пот ярым борчак икән.

— Әйдә йөгерешеп карыйк, кем килеп алыр икән? — диләр дә түгәрәк тышыннан бер-берсенә каршы йөгереп әйләнәләр. Кем иң элек әйләнеп килеп җитсә, җиз бүкән шуныкы була.

## Алдыр чишмә тамчылый

Балалар, икегә бүленеп, бер-берсеннән 20—30 метр ераклыкта тезелеп басалар. Уйнаучылар бер-берсе белән кулга-кул тотынышалар. Беренче яктагылар икенче яктагыларга кычкырып такмаклыйлар:

*Алдыр чишмә тамчылый,*
*Гөлдер чишмә тамчылый,*
*Ал кирәк, гөл кирәк,*
*Бездән сезгә кем кирәк?*

Каршы яктагылар җавап бирәләр:

*Алдыр чишмә тамчылый,*
*Гөлдер чишмә тамчылый,*
*Ал да кирәк, гөл дә кирәк,*
*Роза матур кыз кирәк.*

Исеме чыккан уенчы каршы якны ң сафын йөгереп барып өзеп чыгарга тырыша. Өзә алса, бер уенчыны ияртеп, үз ягына алып кайта. Өзә алмаса, шул якта кала. Уен шул тәртиптә бер якта уенчылар беткәнче дәвам итә.

## Кошлар һәм читлек

Бу уен балаларны тәвәккәл һәм түземле булырга өйрәтә. Ә уенның кагыйдәсе болай.

Уенда катнашучыларның яртысы (8—12 кеше), кулга-кул тотынышып, «читлек» хасил итәләр. Калганнары «кошлар» була. Алар төрле якта «очып йөриләр». Уенны алып баручы хәбәр биргәч, «читлек» ачыла — балалар кулларын югары күтәрәләр. «Кошлар» читлеккә кереп-чыгып йөриләр.

Алып баручы яңада н хәбәр салгач, «читлек» ябыла — балалар, чүгәли төшеп, кулларын төшерәләр. Түгәрәктән чыга алмый калган «кошлар» тотылган дип исәпләнә. Алар да, кулга-кул тотынышып, «читлек» ясаучылар янына басалар.

«Читлек» иркенәя. «Читлек» 3—4 кат ачылып-ябылгач, уенга йомгак ясала. Иң җитезләр билгеләнә. Соңыннан уенчылар урыннарын алмашалар.

*Искәрмә* . Әгәр алып баручы хәбәр салганда «кош»ның башы читлек эчендә кала икән, ул тотылган дип исәпләнә. «Читлек»нең эченә кермичә кырыйда гына «очып йөргән» «кош»лар да тотылганга исәпләнә.

**Яшелчәләр**

Яз көне ишегалдында, болыннарда уйнала торган уен. Балалар арасыннан «бакчачы», «яшелчә алучы» билгеләнеп куела. Балалар бер тирәгә җыелыбрак утыралар, һәм «бакчачы» аларның колагына яшелчә исемнәре әйтеп чыга. Шул вакыт «сатып алучы» килеп ишек кага һәм ике арада шундый сөйләшү була:

— Тук-тук!

— Кем бар?

— Мин.

— Син кем?

— Кеше.

— Нигә килдең?

— Яшелчә алырга.

— Нинди?

— Шалкан (теләгәнен әйтә).

Әгәр яшелчәләр арасында «шалкан» булса, ул торып йөгерә һәм билгеләгән урынны урап килә . Әгәр «сатып алучы» ул арада аны куып тота алмаса, «шалкан» үз урынына килеп утыра, һәм, аңа яңа исем кушылып, уен дәвам итә. Әгәр бала тотылса, ул уеннан чыга. Уен «яшелчәләр» тотылып беткәнче дәвам итә.

**Агачлар да авырый**

Яз башлануга Рәмиләнең әтисе көн дә бакчада була. Ул агач төпләрен йомшарта, корыган ботакларны кисә. Рәмилә әтисе янында йөрергә ярата.

— Әти, агач төбен нигә казыйсың?

— Агач төбен йомшартам, кызым,— ди әтисе.

— Нигә йомшартасың аны? — дип сорый Рәмилә.

— Йомшартмаган агачка су сипкәч, аның төбе катып кала. Су агач тамырларына кадәр үтә алмый. Тамырлар һава да сулый алмыйлар.

— Агачлар да сулыймы?

— Сулый, кызым. Алар өчен дә һава кирәк.

Беркөнне кемдер бакча ишеген ачык калдырган. Шуны гына көткән кәҗә бакчага кереп тә китә. Рәмиләнең әтисе, тиз генә чыбык алып, кәҗәне куып чыгара.

Рәмилә:

— Әти, нигә кәҗәне куасың? — дип сорый.

Әтисе Рәмиләне бакчага алып керә, кәҗә кимерә башлаган агачны күрсәтә.

— Кимерсә ни була?

— Агачларыбыз авырый, яфраклары саргая, үзе корып кала. Аннан соң ул алма бирми башлый.

— Агач та авырыймы?

— Авырый, кызым, хәтта корып, үлеп тә китә.

— Бу алмагач та корыймы инде, әти? — дип сорый ул, еламсырап.

— Бәлки, корымас,— ди әтисе.— Без хәзер бу агачны дарулап, бәйләп куярбыз.

Шуннан соң Рәмилә авыру агач янына көн дә килеп йөри башлый. Ул әлеге агачның бөтерелә, яшеллеген югалта баш лаган яфраклары яңадан яшәрә башлавын күреп куана. Ә беркөнне ул, шатлыгыннан сикерә-сикерә, бакчадан әнисе янына йөгереп керә.

— Әнием, агач терелгән, яфраклары көлеп тора,— ди ул.

*Зәкәрия Әхмәро*в

**Спорт бәйрәме.**

Күңелле балачак» дигән җырның көе астында балалар залга узалар, ярымтүгәрәк ясап кунаклар каршына тезелеп басалар.

Бәйрәмне тәрбияче ача, спортның әһәмияте турында сөйли:

-Исәнмесез, хөрмәтле ата-аналар, кунаклар! Бүген без сезнең белән спорт бәйрәменә җыелдык, алай гына түгел, без дә, сез дә анда катнашып, күңелләрне күтәреп файдалы ял итәрбез дип уйлыйм. Безнең күренекле педагог В.А.Сухомлинский әйтүе буенча: “Сәламәтлек турында кайгырту тәрбиячнең дә, ата-аналарның да иң мөһим хезмәте. Балаларның рухи тормышы, дөньяга карашы, акыл үсеше, белеменең ныклыгы, үз көченә ышанычы, аның көр күңеллелегенә, дәртлелегенә бәйләнгән.”

Сүз балаларга бирелә:

Якты бакча залларында
Яңгырый безнең аваз.
Күңелле безнең балачак
Тормышыбыз яз.

Кояш чыккач, нурга чумгач
Урман, кырлар, аланнар
Сөенеп бакчага киләбез,
Без бәхетле балалар.

Ал бизәкле, гөл бизәкле

Матур безнең бакчабыз.
Уйнап-көлеп, җырлап-биеп
Анда күңел ачабыз.

Тәрбияче: Хәрәкәттә – бәрәкәт
Икәнен онытмагыз,
Бер урында тик торудан
Күгәреп тутыкмагыз!

Безнең бәйрәмне карарга
Дусларыбыз килгәннәр.
Сез әзерме безнең белән
Арыганчы уйнарга?

Күңелле уен башладык
Әйдә рәхим итегез!

“Чебиләр зарядкасы” дигән җырны башкаралар һәм бер үк вакытта кыршаулар, тасмалар, флагчыклар белән төрле күнегүләр ясыйлар.

Кемнәр уйнарга ярата
Кемнәр өлгер һәм җитез
Безнең белән ярышырга
Кемнәр тели әйтегез.

Безнең белән ярышырга
Җитез балалар кирәк.
Кемнәр ярышырга әзер
Чыгып басыйк тизрәк.

Тәрбияче: Ә хәзер без иң җитез, иң көчле балаларны һәм әти-әниләрне белербез.

Балалар 2 командага бүленә.

**1нче уен:**

Ата белән ана кул өсләренә балаларын утыртып, тиешле араны йөгереп узалар.

**2 нче уен:**

Әтисе кулына чиләк тоткан баланы җилкәсенә утырта, ә ана исә билгеле бер ераклыктан кечкенә тупны чиләккә кертергә тиеш.

**3 нче уен:**

Җиргә яны белән тартма куела, шуңа әти-әни һәм бала тупларны тәгәрәтеп кертергә тиешләр.

**4 нче уен**: (җанатарлар өчен табышмаклар)

**5нче уен:**

Әти-әниләр колоннага тезелеп басалар. Һәр колонна башында тәрбияче тора. Командаларга 10-шар туп куела (кәрҗиндә). Сигнал булгач, әти-әниләр бер-берсенә тупны тапшыралар. Колонна ахырындагы кеше тупны тәрбиячегә тәгәрәтә. Тәрбяче тәгәрәткән тупларны җыеп бара. Кайсы команда тупларны беренче җыеп бетерә?

**6 нчы уен:**

2 колоннага да киемнәр бирелә: шапка, шарф, бияләй, чаңгы. Командадагы һәр уенчы киенеп, чаңгы белән билгеләнгән урыннан әйләнеп килә, чишенә, уенны икенче уенчы дәвам итә.

**7 нче уен**: "Җитез балыкчы"

Идәнгә төрле төстәге балык рәсемнәре ясалган 10 карточка чәчелә. Һәр командадан берәр бала чакырыла. Алар кулларына кечкенә чиләк алалар. Сигнал бирелгәч, чиләккә кармак белән тотып балык җыялар. (Кармак – таякка бау, бауга магнит бәйләнә).

Җиңүче командалар билгеләнә, бүләкләү.

**Рәсәй көне уңаеннан әңгәмә**

**Бурычлар:**

1) Балаларның Рәсәй башкаласы – Мәскәү, Татарстан башкаласы – Казан турындагы белемнәрен баету, аларның символикалары турында мәгълүмат бирү.

2) Балаларны рус һәм татар халкының күркәм гореф-гадәтләре, йолалары белән таныштыруны дәвам итү.

3) Балаларда туган илне ярату, аның белән кызыксыну, башка милләт вәкилләренә карата хөрмәт тәрбияләү; балаларның хәтерен, логик фикерләү сәләтен, диалогик сөйләмен үстерү.

**Сүзлек:** тугра, әләм, Рәсәй, бөркет, вәкил, милләт.

**Җиһазлар:** итерактив такта, тема буенча слайдлар, магнитофон, аудиоязмада көй (УМК) "Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе" Методик әсбап өчен аудио-кушымта – 36 һәм 52 нче трек.

**Кулланылган әдәбият:**

1) З.М. Зарипова, Л.Н.Вәҗиева, Р.С.Зөфәрова "Туган телдә сөйләшәбез" (5-7 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча ярдәмлек).-Казан: ФОЛИАНТ, 2012.- 16-17 нче бит;

2) "К.В.Закирова, Р.Ә.Кадыйрова, Г.М.Сафиуллина "Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе: методик кулланма.- Казан: Беренче полиграфия компаниясе, 2013.- 408 нче бит.

**Комплекслы эшчәнлек барышы**

***1) Исәнләшү, бер-береңә карап елмеп, матур итеп.***

Матур итеп елмаеп

Исәнләшик, дусларым.

Малайларым, кызларым,

Исәнмесез, дусларым!

– Исәнмесез. Хәерле иртә! Здравствуйте. Доброе утро! Балалар, без ике телдә дә матур итеп исәнләштек, димәк, сез ике телдә дә сөйләшә аласыз? (Әйе, сөйләшәбез, чөнки ике телне дә белү безгә бик кирәк.).

***2) Кереш әңгәмә.***

-Балалар, карагыз, сез тактада нәрсә күрәсез?

(Без тактада глобус күрәбез). (1 нче слайд-әйләнеп торган глобус).

-Әйе, глобус – җир шарының макеты. Глобуста бөтен илләрне дә күрергә мөмкин: (2 нче слайд – әйләнеп торган глобустан Рәсәй күренеше чыга).

-Балалар, сез монда нинди дәүләт күрәсез?

(Рәсәй дәүләтен күрәбез).

Рәсәйнең башкаласы нинди шәһәр?

(Мәскәү шәһәре).

(3 нче слайд – Рәсәйдән Татарстан күренеше чыга).

Ә монысы нинди республика?

(Татарстан республикасы).

-Дөрес, балалар. Татарстан – Рәсәйнең бер өлеше. Балалар, без нинди республикада яшибез? (Татарстан республикасында).

-Аның башкаласы нинди шәһәр?(Казан шәһәре). Ә без нинди шәһәрдә яшибез?

(Балтач районында ).

Әйе, дөрес, балалар! Безнең республикабызда төрле миләт вәкилләре яши. (4 нче слайд – төрле милләт вәкилләре күренеше). Менә без сезнең белән бүген милләтара дуслык турында сөйләшербез. Дуслык ул – кешеләр, халыклар, дәүләтләр арасындагы үзара мөнәсәбәт, бәйләнеш.

-Балалар, безнең балалар бакчасына ниди милләт вәкилләре йөри әле? (Татар миләтенннән һәм рус милләтеннән балалар йөри).(5 нче слайд – безнең балалар бакчасы балалары).

-Әйе, күбесенчә татарлар һәм руслар. Һәм без үзара тату, дус булып яшәргә тырышабыз. Менә бүген дә алар безнең арада.

***2) Яңа материал өстендә эш.***

(Рус халык көе яңгырый, шул көйгә рус миләте киеменнән киенгән малай һәм кыз чыга).

-Балалар, ничек уйлыйсыз, бу кайсы миләт вәкилләре икән?

(Рус миләте вәкилләре).

-Каян белдегез, балалар?

(Киемнәреннән).

-Әйе, дөрес! Һәрбер илнең үз әләме һәм туграсы да бар.Әйдәгез, балалар, карап һәм тыңлап китик, нинди икән алар. (6 нчы слайд – Рәсәйнең туграсы һәм әләме рәсеме).

1 нче бала (малай):

Наш герб – очень гордая птица,

С двумя головами орёл.

Одной он глядит на Европу,

В Азию взгляд у другой.

2 нче бала(кыз):

Флаг бывает разный,

Но мне всего милей
Бело-синий-красный
Флаг родины моей.

-Рәхмәт, балалар! Димәк, Рәсәйнең әләмендә нинди төсләр бар?
(Ак, зәңгәр, кызыл).
-Ә туграда нәрсә сурәте төшкән?
(Туграда ике башлы бөркет сурәте).
-Дөрес.

Кыз әйтә: Без сезгә хәзер рус халык биюен биеп китәбез!
(Кыз белән малай башкаруында рус халык биюе башкарыла).

-Рәхмәт сезгә, балалар!
Татар халык милли көе яңгырый. (Татар халык милли киеменнән малай һәм кыз чыга).
-Ә хәзер Алмир белән Ләйләгә сүз бирәбез.

1 нче бала (малай):
Мин бит татар малае,
Арчам – өем минем.
Мин бит татар малае,
Татарстан – илем минем.

2 нче бала(кыз):
Дөньяга аваз салдым
Мин татар гаиләсендә.
Әти-әни өйрәтте
Татарча сөйләшергә.

-Татарстанның да үз әләме белән тугрАсы бар. Алар нинди икән, карап һәм тыңлап китик! (7 нче слайд – Татарстанның әләме һәм тугрАсы).

1 нче бала (малай):
Өч төс балкый безнең әләмдә:
Ак төс – безнең намус төсебез.
Яшел төсе – безнең яшәү төсе.
Кызылында чагыла көчебез.

2 нче бала(кыз):
Ак барс безнең тугрАбызда,

Саклый ул халкыбызны.

Зур үрләргә, алга өнди

Гүзәл Татарстаныбызны!

-Рәхмәт. Балалар, димәк безнең туган илебез әләмендә нинди төсләр бар?

(Ак, яшел, кызыл).

-Дөрес, ә туграбызда нәрсә сурәте күрсәтелгән?

(Туграбызда ак барс сурәте күрсәтелгән).

Малай: Безнең халыкта бик күп матур уеннар бар. Әйдәгез бергәләп **“Зәңгәр чәчәк” уенын**уйнап алыйк! (Шуннан соң башка балалар белән татар халык уены “Зәңгәр чәчәк” уйнала.)

Балалар, кулга –кул тотынышып, түгәрәк ясыйлар. Бер бала чигүле кечкенә мендәр тотып уртага чыгып баса. Балалар түгәрәк буенча җырлап әйләнәләр:

Юл читендә зәңгәр чәчәк

Якты нурлар тарата.

Безнең кызлар һәм малайлар

Зәңгәр чәчәк ярата.

Туктап биеп-җырлап торалар, ә уртадагы бала мендәр тотып түгәрәк буенча биеп йөри.

Якын дуслар арасыннан

Берсен сайлап ал әле.

Тезләреңә ипле булыр –

Мендәреңне сал әле.

Мендәр тоткан бала мендәрен бер бала алдына куя һәм, тезләнеп, аңа кулын бирә. Ул бала аның тирәли әйләнә, башкалар кул чабып торалар.

***3) Балалар эшчәнлеге.***

-Рәхмәт, балалар! Чыннан да бик күңелле уен. Хәзер мин сезнең бүгенге эшчәнлектә алган белемнәрегезне тикшереп китәм. Барыбыз да тактага карыйбыз. Сез шунда бирелгән төсләрдән Рәсәй һәм Татарстанның әләмен ясый алырсызмы икән?! (Бирелгән төсләрдән сайлап Рәсәйнең һәм Татарстанның әләмен ясау).

***3) Нәтиҗә ясау.***

-Рәхмәт сезгә, балалар! Менә без рус һәм татар халкының символикалары, матур гореф-гадәтләре, йолалары белән таныштык. Һәр халыкның үз гореф-гадәтләре, йолалары искиткеч матур һәм бай! Һәм һәр халыкны дуслык бәйли, туганлаштыра! Ә хәзер барыбыз да “Дулык җыр”ын җырлап китәбез!

***4) Йомгаклау.***

Эшчәнлек “Дуслар җыры” (Рафис Корбан сүзләре,Фуат Әбүбәкер музыкасы) белән тәмамлана.

1) Дуслар белән күңелле,

Яшәве рәхәт.

Дустым булганың өчен

Сиңа зур рәхмәт.

Кушымта:

Син минем якын дустым,

Мин синең дустың.

Яхшы һәрвакыт янда

Булганы дусның!

2) Безнең дуслык нык булсын,

Мәңгелек булсын!

Көннәребез гел шулай

Шатлыкта узсын!

**Уенчыклар көне**

Максат: 1. Балаларны матур итеп исәнләшү, рәхмәт, сау булыгыз, хәерле көн сүзләрен сөйләмдә куллануны өйрәтүне дәвам итү;
2. Өйрәнгән уенчык исемнәрен ныгыту;
3. Уенчыкларга сакчыл караш тәрбияләү;
4. Балаларда татар телен өйрәнү теләге тудыру, кызыксыну уяту.
Җиһазлар: Уенчыклар - курчак, песи, эт, аю, тычкан, туп.
Шөгыль барышы:
Тәрбияче: - Исәнмесез, балалар. Хәлләрегез ничек? Хәерле көн сезгә.
Балалар: - Әйтелергә тиешле жаваплар ( исәнмесез, әйбәт, хәерле көн).
Тәрбияче: - Балалар, сез уенчыклар белән уйнарга яратасызмы? Уенчыклар иленә сәяхәткә чыгасыгыз киләме?
Балалар: - Әйтелергә тиешле жаваплар (яратабыз, әйе).
Тәрбияче: - Сәяхәткә паровозда чыгарбыз. Әйдәгез, утырыгыз, киттек. (Балалар тәрбияче артына тезелешеп басалар). Паровоз ничек сигнал бирә?
Балалар: - Әйтелергә тиешле жавап (У-у-у).
Тәрбияче: - Киттек. Чух – чух – чух, чух – чух – чух.
Беренче “Курчак” тукталышы. Чаршау артында өстәл, өстәлдә ипи, конфет, чәкчәк, өчпочмак. Курчак урындыкта утыра.
Тәрбияче: - Без беренче тукталышка килеп җиттек. Карагыз әле, бу нәрсә? (Тәрбияче курчак күрсәтә).
Балалар: - Әйтелергә тиешле жавап (курчак).
Тәрбияче: - Дөрес, балалар. Безнең курчак чәй эчәргә җыенган. Әйдәгез, курчакка өстәл әзерләргә булышабыз. Өстәлгә нәрсәләр куярга кирәк?
Балалар: - Әйтелергә тиешле җаваплар (тәлинкә, чынаяк, кашык, чәйнек).
Балалар тәрбияче ярдәмендә өстәлгә чәйнек, чынаяк, тәлинкә, кашык куялар.
Икенче тукталыш - “Йомшак уенчыклар”.
Тәрбияче: - Балалар, карагыз әле, бу тукталышта нинди уенчыклар күрәсез?
Балалар: - Әйтелергә тиешле җаваплар (песи, эт, тычкан, аю).
Тәрбияче: - Әйтегез әле, безнең тычкан нинди?
Балалар: - Әйтелергә тиешле җаваплар (тычкан кечкенә, матур).
Тәрбияче: - Песи нинди?
Балалар: - Әйтелергә тиешле җаваплар (песи матур, кара, зур).
Тәрбияче: - Эт нинди?
Балалар: - Әйтелергә тиешле җаваплар (эт зур, матур, сары).

Тәрбияче: - Аю нинди?
Балалар: - Әйтелергә тиешле җаваплар (аю зур, ак, матур).
Тәрбияче: - Дөрес, балалар. Ә хәзер тактадагы рәсемгә карыйк. Аюның бер аягы юк. Кемдер өзгән. Шулай эшләргә ярыймы? Уенчыклар белән ничек уйнарга кирәк?
Бу сорауга балалар тәрбияче ярдәмендә җавап бирәләр.
Тәрбияче: - Әйдәгез, аюның аягын ясап куябыз. Ул безгә рәхмәт әйтер.
Өченче тукталыш - “Туплар” тукталышы. Кәрзиндә төрле зурлыктагы туплар.
Тәрбияче: - Менә өченче тукталышка да килеп җиттек. Бу тукталышта нинди уенчыклар?
Балалар: - Әйтелергә тиешле җавап (туплар).
Тәрбияче: - Алар нәрсә белән аерылалар?
Балалар: - Әйтелергә тиешле җаваплар (зур, кечкенә).
Тәрбияче: - Әйдәгез тупларны зурдан кечкенәгә тезеп куябыз. Сез саный беләсезме? Монда ничә туп?
Балалар бергәләп тупларны зурдан кечкенәгә тезәләр, санайлар.
Тәрбияче: - Булдырдыгыз, балалар, яхшы эшләдегез. Сәяхәтебез шуның белән тәмам. Без бүген нинди уенчыклар тукталышында булдык?
Балалар: - Әйтелергә тиешле жаваплар (курчак, йомшак уенчыклар, туплар).
Тәрбияче: - Дөрес. Бүгенгә безнең шөгыльләребез бетте. Барыгызга да рәхмәт. Уенчыклар белән матур итеп уйнагыз, вата күрмәгез. Сау булыгыз.

**Кыр чәчәкләре көненә әңгәмә**

Бу айда бал кортлары армый-талмый эшлиләр, бал җыеп калырга тырышалар. Бөтен җирдә хуш ис, чәчәкләр исе, бал исе. Матурлык. Бер ел фасылы белән дә тиңләштереп булмый торган матурлык. Җир – гаҗәеп матур келәм. Аның бизәкләре – чәчәкләр. Ниндиләре генә юк аларның. Июньдә кешеләр дару үләннәре җыялар. Чөнки күп кенә дарулар чәчәкләрдән ясала. Без барыбыз да чәчәкләр яратабыз. Бакчаларыбызда нинди генә чәчәкләр үсми. Анда җәй буе, тирә-юньгә ямь биреп, розалар, кашкарыйлар, ап-ак ромашкалар, аллы-гөлле лаләләр, төрле төстәге лилияләр шаулап утыралар. Без аларга көн дә су сибәбез, чүп үләннәрдән арындырабыз, алар белән сөйләшеп йөрибез, чөнки чәчәкләр җанга тынычлык бирәләр, кәефебезне күтәрәләр. Чәчәкләр, тирә-якка ямь биреп, тормышыбызны бизәп торалар. Алар урамнарны, паркларны бизи, шәһәр-авылларны матурлый, бәйрәм төсе бирә, кешеләрне шатландыра. Табигать чәчәкләрне җирне матурлау өчен үстерә. Кешеләр табигать матурлыгын бозмаска, сакларга тиешләр. Урман-кыр чәчәкләре дә саклауга мохтаҗ.

Чәчәкләр өй яннарында, бакчада, болыннарда, урманнарда, су буйларында үсәләр. Мәсәлән, болында һәм урманнарда үскән ромашкаларны гына алыйк. Урманныкы эре, таҗ яфраклары киң, ә болында үскәне – вак, таҗлары да тар була. Ни өчен алай дисезме? Чөнки болында дым аз, ә урманда күп. Урманда чәчәкләр ышыкта, җил-яңгырдан сакланып торалар, ләкин аларга кояш яктысы, кояш җылысы җитеп бетми.

Иң гүзәл чәчәкләрнең берсе – роза чәчәге. Ул – төрле авыруларга дәва. Согын төрле мазьларга кушалар. Порошогын бал белән кушып, авыз эче бозылганда файдаланалар. Чәчәген уып, баллы су белән эчеп тән температурасын төшерәләр. Аңардан төрле майлар ясыйлар. Роза чәчәге беренче булып Вавилонда үстерелә, 19нчы гасырда аның турында беренче китап языла, ә Мичурин розаның яңа сортларын чыгара. Татарстан җирендә розаның 15 төре үстерелә.

Матурлыгы, тыйнаклыгы белән күңелләрне җылыткан башка чәчәкләребез дә бихисап. Мәсәлән, Миләүшә яки фиалка чәчәге әнә шундыйлардан. Фәндә аны фиалка дип, ә безнең телдә миләүшә дип, русларда Иван да ”Марья“, ”Девичьи глаза“, ”Анютины глазки“ дип йөртәләр. Ул халыкның яраткан чәчәге, яз килүен, табигать уянуын хәбәр итә.

Бик күп әкиятләр, риваятьләр тууга сәбәпче булган тагын бер хуш исле, гүзәл чәчәк – энҗе чәчәк – ул ландыш. Ул бик кыйммәтле үсемлек, табигать баласы, илһам чыганагы. Дәвалау

өлкәсендә дә борын-борыннан аны беләләр. Ландыш чәчәкле кешеләргә шайтан таягы кебек ышанычлы кеше кирәк, чөнки ул артык киң күңелле, ышанучан.

Тагын бер чәчәк – кәнәфер чәчәге. Кәнәфер чәчәге – мәхәббәт билгесе, ирек өчен көрәш символы ул. Кәнәфернең дәвалау үзенчәлекләре бар. Ул йөрәкне, башны, ашказанын дәвалый. Ашкайнату эшчәнлегенә, күзләрнең яхшы күрүенә булыша. Кәнәфердән алынган хуш исле май парфюмериядә кулланыла.

Димәк, чәчәкләр шатлык һәм матурлык чыганагы. Алар безнең тормышыбызны бизи, рухыбызны күтәрә, кешеләр арасында эчкерсез дуслык билгесе булып та хезмәт итә.

**Уен-колке көне**

**Җыр “Көләсе килеп тора”**

Нинди матур көн бүген
Көләсе килеп тора.
Минем көлгәнне күреп,
Кояш та көлеп тора.

**Кушымта:**
Хи-хи-хи, ха-ха-ха
Көләсе килеп тора.
Хи-хи-хи, ха-ха-ха
Хи-хи-хи, ха-ха-ха.

Кояшка карап бөтен,
Гөлләр дә көлеп тора.
Алар да көннең матур,
Икәнен белеп тора.

Бакчада гөлләремнән
Хуш ис бөркелеп тора.
Мин үстергән гөлләр дип
Бар кеше белеп тора.

**“Чәчтем шалкан”шигыре (Г.Зәйнашева)**

Чәчтем шалкан, чыкты кишер,
Җыеп алдым чөгендер.
Кып-кызыл эре чөгендер,
Һич тә ялган түгелдер.
Чөгендерне кайнаттым да
Ясадым ап-ак шикәр.
Шундый тәмле шикәр чыкты,
Исең акылың китәр.
Шикәрнең вак-вак кисәген
Чәчтем җиргә мин кабат,
Түтәл, түтәл, түтәл булып
Үсте җирдә шоколад!
И йөрим, йөрим бакчада
Ашап шоколад кына
Һич тә ялган сөйләмимен,
Арттырамын чак кына.

**Ш.Галиев “Көлегез”**

Кояш бөтен кешегә дә,
Бертигез көлеп карый.
Көлү бит ул гөнаһ түгел
Һәммәбезгә дә ярый.
Сау-сәламәт таза була,

Шаярган, көлгән кеше.
Көлеп эче авыртса да,
Авыртмый бүтән төше.
Тырышыйк, зур өлеш кертик
Без көлү өлкәсенә.
Тик үзебез генә калмыйк
Әй адәм көлкесенә.

**Колаклы коймаклар.**

Апам коймак пешерде
Беренче тапкыр.
Коймаклар шундый тәмле
Һәм шундый матур.
Майлы һәм баллы булганга
Яраттык коймакларны,
Ләкин алар гади түгел,
Бар нәни колаклары.
Кайсында биш, кайсында өч
Кайберләрендә алты.
Колаксызлар бөтенләй юк
Берсе ярты колаклы.
Майга буялды бармаклар,
Иреннәр, колаклар да.
Үзебез дә охшап калдык
Колаклы коймакларга.

**Авылга цирк килгәч.**

Зур яңалык бу елда-
Цирк килде авылга.
Әй җыйналды малайлар,
Апайлар һәм агайлар.
Әбиләрне әйткән дә юк,
Әтиләр килгән хәтта.
Сакаллы сабый- бабайлар
Алда беренче рәттә.
Ат биетәләр уртада
Ял төпләре ак күбек.
Әй, шатлана авыл халкы
Беренче күргән кебек.
Юбка кигән мәчеләргә,
Җигелгән эткә карап.
Ул кул чаба карты-яше
Шатлана, бер дә харап.
Өйрәтә белгәннәр, имеш,
Сарык белән кәҗәне...
Цирк карый авыл халкы
Артта дөньяның яме.

**“Алдаганчы уйлагыз”( Гүзәлия Ганиева)**

Алдау көне җитә, диеп
Искә төшерде улым.
Балачак ялгышларымны
Хәтеремнән уздырдым.
Күршебездәге карчыкны
Мин шул көнне алдадым.
Өлкән кеше, ярамас, дип,
Уема да алмадым.
-Мунча якты бүген әни,

Кереп чык, бер юынып.
Китте әби чабынырга
Беткәнче дип суынып.
Шул вакытта сөенүем:
Әбине бит алдадым.
Зур гөнаһлы булганымны
Еллар үткәч аңладым.
Суык мунчага кергәчтен
Улниләр уйлагандыр.
Рәнҗемәде микән, диеп
Алдау көне килеп җиткәч
Һәр елда уйланамын.

**Такмаклар**

Иртән торып тышка чыксам,
Кәҗә көтү төшерә.
Табаларын кыра-кыра
Әтәч коймак пешерә.

Иртүк торып тышка чыксам,
Кырмыска утын кисә.
Кәкре каен гармун уйный,
Сыер танцевать итә.

Ике тавык җырлап йөри,
Әтәч гармун уйната.
Шул тавышка чыдый алмый
Ата каз елап ята.

Чуар тавык суга бара,
Аягында чабата.
Шул вакытта оялмыйча
Ата каз йоклап ята.

Безнең песи бигрәк уңган,
Комганга су тутыра.
Бозавыбыз мич башында
Оек бәйләп утыра.

**Кызыклы сораулар.**

- Ни өчен арысланнар чи ит ашыйлар?( пешерә белмәгәнгә)
- Карга 3 ел яшәгәч нишли?( 4 яшь китә)
- Суны иләк белән ничек ташып була?(катырып)
- Кара мәчегә өйгә керүе кайчан җайлырак?( ишек ачык булганда)
- Кошны куркытмыйча гына агач ботагын ничек сындырып алырга?(кош очып киткәнен көтәргә)
- Апельсинның яртысы нәрсәгә ошаган?( икенче яртысына)
- Яңгыр яуганда карга нинди агачка утыра?( юеш)
- Теше бар, авызы юк. Бу нәрсә?( пычкы)
- Ике сарык басып тора: берсенең башы төньякка, икенчесенеке көньякка караган. Башларын бормыйча гына алар бер-берсен күрә алырлармы? (алар бер-берсенә карап тора)
- Нәрсәне әзерләп була, тик ашап булмый? (дәрес)
- Нинди читлектә кошларны һәм хайваннарны тотып булмый? (күкрәк читлегендә)

**Экспериментлар оештыру**

***1 нче эксперимент*.**

Без тематик атналар белән эшлибез. Диңгезләр, сулыклар темасын үткәндә, олылар һәм мәктәпкә әзерлек төркемендә бу экспериментны эшләп була.

**Тозлы диңгез суында йомырка батмый.**

*Безгә нәрсәләр кирәк:* бер яки ике тавык йомыркасы, ике савыт яки 1 литрлы банкалар, аш тозы, су.

*Тәҗрибә.* Бер савыт суны шул килеш калдырабыз, ә икенче савытта ярты стакан тоз салып эрегәнен көтәбез. Беренче нәтиҗә – тоз суда эри. Ике савытка да йомырка салабыз.

*Нәтиҗә.* Төче суда йомырка батты, ә тозлы суда батмады.

Һәрбер тәҗрибә яки эксперементтан соң нәтиҗә ясыйбыз, шул ук вакытта икенче эзләнү үткәрү өчен орлык салып куябыз. Бу очракта нинди сорау куеп була? *Кеше дә тозлы суда яки диңгездә батмый микән? Ни өчен шулай булды бу?* Без йомгак ясап балага алдагы эзләнүләргә максат куябыз. "*Менә шушы китаптан карагыз, әти-әниләрдән сорагыз, фәнни-популяр передача карагыз".*

***2 нче эксперимент.***

"Космос" тематик атналыгы җитте. Нәрсә ул космос? Йолдызлар хәрәкәтләнәме? Нәрсә ул галактика? Бу сорауларга җавапны аңлатып биру бик авыр, чөнки тотып карап булмый. Миңа**"Кечкенә галактика"** дигән тәҗрибә ярдәмгә килде.

*Нәрсәләр кирәк:* Бер савыт су, конфетти яки ялтыравыклар, таяк.

*Тәҗрибә.* Савыттагы суны кечкенә космос дип күз алдына китерәбез. Нәрсәләр җитми? Төнлә күккә карагач без нәрсәләр күрәбез? Әйе, йолдызлар. Алар нинди? (Кечкенә һәм ялтырап торалар). Суга кечкенә ялтыравыклар салабыз, таяк белән болгатып җибәрәбез. Балалар, карагыз, йолдызлар космоста менә шулай хәрәкәтләнәләр икән. Безнең йолдызыбыз Кояш та шулар арасында. Бер якка әйләнеп йөрүче йолдызлар барысы бергә "галактика" дип атала. Кабатлап әйтегез һәм истә калдырыгыз.

*Нәтиҗә.* Йолдызлар тик тормый, хәрәкәтләнәләр. Галактика бергә хәрәкәтләнүче йолдызлар җыелмасы.

*Эзләнү өчен сорау.* Без нинди галактикада яшибез? Тагын шундый галактикалар бармы икән?

***3 нче тәҗрибә-эксперимент.* "Тылсымлы стаканнар".**

Тәрбияче психолог та булырга тиеш. Күп вакытта балалар үзләренең эмоцияләрен аңлап бетермиләр, нәтиҗәдә контрольда тота алмыйлар. Алдагы эксперимент аларга кеше эмоцияләренең күптөрлелеген күрергә һәм аңларга ярдәм итә.

*Безгә кирәк:* чиста су салган үтәкүренмәле стаканнар, коктейль трубкалары, кызыл, сары һәм кара гуашь краскалары, пумала, ялтыравыклы пайеткалар.

**Эксперимент барышы.**

-Балалар, без сезнең белән хәзер "Тылсымлы стаканнар" дигән тәҗрибә үткәрербез. Менә сезгә таяклар һәм сулы стаканнар.

Без тыныч вакытта, үз-үзебезне яхшы хис иткәндә, барысы белән канәгать булганда, безне бер нәрсә дә борчымаганда безнең кәефебез менә шушы стакандагы су шикелле чиста. Шушы чиста һәм үтә күренмәле тыныч суга карагыз, безнең фикер уйларыбыз да шундый чиста, тыныч. Без елмайганда, шаярганда безнең кәефебез дә искиткеч шатлыклы, сокландыргыч ә уйларыбыз салютка ошаган: ялтырыйлар, уйнаклыйлар. Менә бу стакандагы су шикелле. (Стакандагы суга ялтыравыклы пайеткалар ата һәм болгатып җибәрә) Карагыз, нинди матурлык! Сез дә шулай сихерләп карагыз. Менә бу подноста безнең зур шатлык-соенечләребез җыелган. Азрак шатлык алыгыз да, стаканга салыгыз, таякчык белән болгатып җибәрегез. Иснәп карагыз әле, бәлки шатлык исе дә киләдер? Сезнең бик матур салют килеп чыкты бит! Мин бик шатмын!

Кызганычка каршы кәефләребез гел шулай яхшы булмый шул. Кемдер яки нәрсәдә булса кәефебезне боза, яки безне кыерсыталар, елыйсы килә. Безнең уй-фикерләребез моңсу, күңелсез, без үзебезне начар хис итәбез, бу вакытта алар пычрак, болганчык суны хәтерләтә. (Кара буяу белән суны пычратабыз) Бу безнең шатлыгыбыз югалганны күрсәтә. Кәефебез начарланды. Шатлык сөенечләрне ничек кайтарырга соң? Һәрберегез үзенең фикерен әйтсен. (Балалар төрле юллар табып

әйтәләр һәм тәрбиячәнең савытына үз савытларыннан аз гына су салалар). Карагыз әле, сезнең тырышлык белән минем кәеф ничек яхшыланды! Рәхмәт сезгә!

Шундый хәлләр дә булгалый: кемдер талаша, ачулана һәм йодрыкларын йомарлый. Кеше ярсый. (Кызыл буяулы пумала белән суны кызыл төскә кертә) Су нинди төскә керде? Ачулы кешенең бите дә шундый була бит. Кешенең эчендә әшәкелек, ачу болгана. (Трубка белән өреп суны болгатабыз) Исегезгә төшерегез әле, ни өчен сезнең ачуыгыз чыга иде? (Балалар җавап бирәләр һәм үзләренең суларын буыйлар) Бу әшәке уйларны җиңү өчен ни эшләп була соң? (Җавап биргән балаларга сары төс белән суларын буятабыз) Карагыз, су нинди төскә керде? Бу төс нәрсәне аңлата микән?

**Максат** : 1. Балаларда спорт белән кызыксыну уяту, спортның кеше тормышындагы әһәмиятен аңларга булышу.
2. Балаларда бердәмлек хисен тәрбияләү.
**Әзерлек эшләре**: 1. Катнашучы укучылар 2 командага бүленә.
2. Һәр команда үзенең эмблемасын, девизын әзерли.
3. Грамоталар әзерләү.
**Уенның барышы:**
Катнашучы командалар тезелеп басалар.
**Кереш сүз.**
Исәнмесез. Без сезнең белән күңелле стартлар уены үткәрергә җыелдык. Сәламәтлек ул- спорт, физкультура белән шөгылльләнү,чыныгу, сәламәт яшәү рәвеше алып бару, һәм , әлбәттә, барысын да җиңеп чыгу өчен белемнәр һәм дуслык. Бәлки, сезнең берегез киләчәктә данлыклы спортсмен булыр, үзебезнең төбәгебезнең данын яклар. Россия спортсменнары белән Олимпия уеннарында катнашыр .
Ә хәзер әйдәгез уенны башлыйбыз. Үзебезнең команда өчен тырышып , очколарыбызны китерәбез. Башта хөрмәтле жюри составын сайлыйк. Алар безнең җитезлегебезне, бердәмлеге- безне билгеләп утырырлар.

1. **Командалар белән таныштыру.**
   Командалар үзләренең эмблемалары, девизлары белән таныштыралар.
   “**Җир”** командасы:
   Хәрәкәттә-бәрәкәт!
   Тәнгә кирә көч һәм дәрт,
   Тәнгә-сихәт, җанга-рәхәт,
   Хәрәкәткә мең рәхмәт!

   “ **Галәм”** командасы:
   Күрәсезме барыбыз да
   Сәламәт, йөзебез шат.
   Сәламәт буласың килсә!
   Спортны ярат!

2. Традиция буенча Олимпия уеннары ачылганда изге утны яндыралар. Ул ут бер уенчы- дан икенче уенчыга бирелә. Без дә уеныбызны Олимпия утын бирүдән башлыйбыз.
   **Эстафета “Олимпия утын йөртү”** дип атала.

   Капитаннарга флажоклар бирелә. “ Марш” командасы булу белән , капитаннар алга йөгерәләр. Финишка барып җиткәч, кире старт сызыгына йөгереп килә, флагны икенче уенчыга тапшыра. Үзе колонна ахырына барып баса. Икенче уенчы йөгереп китә. Ул
   шуны ук кабатлап чираттагы укучыга бирә. Иң соңгы укучы йөгереп барып килгәч, капитанга флажокны бирә. Ул флажокны өскә күтәрә, ә калганнар кулларын ян-якка сузалар.

3. **« Пингвиннар”**

Капитан ике тез арасына туп кыстырып финиш сызыгына кадәр сикереп бара. Контроль сызыкка килеп җиткәч тупны кулга тотып йөгереп килә һәм икече уенчына тапшыра. Һәр уенчы шуны ук кабатлый. Туп төшкән очракта , уенчы тупны алып уенны дәвам итәргә тиеш. Эстафетаны беренче бетергән команда җиңүче була.

4. “ **Сәламәт кешегә барсы да әйбәт” (“Здоровому - всё здорово”)**
Америка галимнәре тикшерүләр үткәргәннән соң, кеше көлгәндә аның үпкәсенә 3 тапкыр күбрәк һава кергәнен ачыклыйлар. Шулай булгач сәламәтлек өчен рәхәтләнеп көлеп алабыз! Кайсы команда катырак көлә шул җиңүче була.

5. “ **Капчык киеп йөгерү”**

6. “**Теннис ракеткасы һәм шары эстафетасы”.**
Атлап барганда ракетканы тоткан кулны сузабыз. Анда шар куелган. Икенче кул белән шарны тотасы түгел.

7. “ **Туп йөртү”**
Уенчылар үз урыннарында басып торалар. Кулларын баш өстенә күтәрәләр. Чират буенча тупны баш өстеннән җибәрәләр. Ахыргы уенчы алга килеп тупны артка җибәрә. Уен капитан кире үз урынына кайтканчы уйнала.. Капитан тупны ала һәм кулын алга суза.

8. “ **Зур башмак” эстафетасы.**
Балалар аякларына зур башмак ( коробка) киеп финишка баралар һәм кире киләләр. Башмакны икенче уенчыга тапшыралар.

9. “ **Көнгерә”**
Кайсы команда ераграк сикерә? Команда членнары чираттан урыннан ераклыкка сикерәләр. Һәр чираттагы уенчы алдагы сикерүченең баскан урыныннан сикерә башлый.
Сикергән кеше урыныннан икенче уенчы килгәч кенә китә.Ераграк сикергән команда җиңүче була.
( жюриларыбызның бик тә игътибарлы булуын сорар идек)

10. “ **Вагон төзү” эстафетасы**
Капитан стена янына кадәр йөгереп бара һәм кире йөгереп килә. 2 уенчыны җитәкләп йөгерә.Шулай итеп соңгы уенчыга кадәр йөгерәләр. Барлык уенчы йөгереп бетергәч, үз урыннарына кайтып тезелергә тиешләр.

11. “ **Кегльләр”**

Капитаннар өчен конкурс. 2 капитанга да бер үк ераклыкта кегль куела. Сигнал булуга тупны тәгәрәтеп кегльне аударырга кирәк. Кегльне аударганны җиңүче була.

13. “ **Атта йөрүчеләр”**
1 уенчы обручны кия. 2 уенчы обручтан тота. Финишка кадәр һәм кирегә йөгерәләр. Эстафетаны чираттагы ике уенчыга тапшыралар. Һәрбер пар йөгереп бетергәч, капитан обручны ике кулы белән алда тотып торырга тиеш.

**Йомгаклау .**

Уеныбыз ахырына якынлашты. Хәзер сүзне жюрига бирәбез. Кайсы команда иң тиз, игътибарлы, дус һәм спорт сөючән икәнен беләчәкбез.

Жюри ярышка йомгак ясый. Грамоталар тапшырыла

**Шаяру көненә уеннар**

**Җырлы – биюле уен «Уенга җыю җыры»**

Балалар төрлесе төрле шөгыль белән мәшгуль вакытта, уен башлаучы бала уенга җыю җырын башкара. Башка балалар, әкрен-әкрен генә уенчыкларын, эш коралларын җыеп, иптәшләре янына уенга җыелалар, җырга кушылып җырлыйлар.

Уен башлаучы

*Әйдәгез, дуслар, җыелыйк,*

*Җитәкләшеп тезелик.*

*Түгәрәктә бергәләп*

*Күңелле уйныйк, көлик!*

*Зурлар безгә соклансын,*

*Читтән карап торсыннар,*

*Безнең дуслыкка сөенеп,*

*Бертуган дип белсеннәр.*

Балалар

*Чү, әйдәгез, без теләгәнчә*

*Уйныйк, шау-шу килик,*

*Яшь чагыбыз, шат чагыбыз –*

*Шатланыйк, сөеник, көлик!*

*Чү, тыймагыз, тик торыгыз*

*Карап сез читтә генә,*

*Нинди матур гөр киләбез,*

*Чабып-сикереп менә!*

*Дәртле, җанлы, без күңелле,*

*Безгә ямьле Җир йөзе,*

*Безгә карап елмая*

*Күкнең кояшы, ай-йолдызы.*

**2**

**Җырлы – биюле уен «Парлашып калу»**

Балалар түгәрәккә басып, җырлап йөриләр:

*Сандугачлар, былбыллар,*

*Тургайлар парлы була.*

*Кем уенда парсыз кала,*

*Шундук җәзасын ала.*

Җыр бетүгә, бию көе башлана. Балалар бииләр. Бию көе туктагач, тиз генә парлашып басалар (балалар саны так булырга тиеш). Так калган балага җәза бирелә (җырлый, бии һ. б.)

**3**

**Җырлы – биюле уен «Үрмәкүч»**

Уен түгәрәктә уйнала. Уртада бер бала «үрмәкүч» булып чүгәләп утыра. Балалар түгәрәк буйлап җырлап йөриләр. Җырның соңгы сүзеннән соң үрмәкүч сикереп тора, түгәрәктәге балалар берьюлы чүгәлиләр.

*Менә чебеннәр парлашып, туйганчы биеделәр,*

*Йөри торгач, барысы да арыдылар, талдылар.*

*Әйләнделәр, борылдылар, як-якка күз салдылар,*

*Үрмәкүчне күргәннән соң, хушларыннан яздылар.*

**4**

**Җырлы – биюле уен «Ак калач»**

Балалар зур түгәрәк ясап басалар. Бер бала түгәрәк уртасында басып тора. Балалар, түгәрәк эчендәге баланың исемен әйтеп, тә түгәрәк буйлап җырлап йөриләр: «җәелгән» сүзендә түгәрәкне киңәйтәләр; «кабарган» дигәндә, кулларын бергә күтәрәләр; «кечкенә» дигәндә, барысы бергә уртага керәләр (кысылалар); «зур» сүзендә янә түгәрәкне киңәйтәләр һәм ахыргы сүзләрдә, тиз-тиз җырлап, кулларын чәбәклиләр. Бу вакытта уртадагы бала уйнаучылардан берәүне уртага чыгара. Уен, икенче баланың исемен әйтеп, кабат башлана.

*Галиянең туган көненә*

*Без пешердек ак калач,*

*Менә шулай җәелгән,*

*Менә шулай кабарган,*

*Менә шулай кечкенә,*

*Менә шулай зур гына.*

*Ак калач, ак калач,*

*Теләгәнеңне сайлап кач!*

*Ак калач, ак калач,*

*Теләгәнеңне сайлап кач!*

**5**

**Җырлы-биюле уен «Коймак»**

Уйнаучылар, кулга-кул тотынышып, түгәрәккә тезеләләр. Бер бала уртада басып тора. Беренче куплетта балалар түгәрәк буйлап җырлап йөриләр.

Икенче куплетның беренче һәм икенче юлларын җыр- лаганда, балалар кулларын, ычкындырып, өскә күтәрәләр; өченче юлында – як-якка җәяләр; дүртенче юлда ике кул тоташа.

Өченче куплетта балалар кул чабып торалар, ә уртадагы бала түгәрәктән бер баланы сайлап ала. Алар, кулларын тотышып, кара-каршы басалар һәм әйләнәләр.

*Булатның туган көненә*

*Без чакырдык кунаклар.*

*Кунакларның килүенә*

*Без пешердек коймаклар.*

*Коймакларга карасаң,*

*Менә шулай кабарган,*

*Менә шулай җәелгән,*

*Менә шулай кысылган.*

*Коймагыңны майлап ал,*

*Теләгәнең сайлап ал.*

**6**

**Җырлы – биюле уен «Сукыр тәкә»**

Бер баланы, күзен бәйләп, уртага бастыралар. Ул – «сукыр тәкә». Калган балалар кырыйда җырлыйлар:

*Сукыр тәкә йөгерә,*

*Күрми ул бернәрсә дә.*

*Йөгермичә нишләсен,*

*Тота алмый берсен дә.*

Җыр беткәч, балалар сукыр тәкәгә якын килеп, кагылып китәләр. Сукыр тәкә куа. Кемне дә булса тотса, тотылган бала «сукыр тәкә » була. Уен шулай дәвам итә.

**7**

**Җырлы – биюле уен «Наза»**

Балалар парлашып, бер-бер артлы тезелеп басалар. Бер бала ялгыз кала, ул уенчыларның каршына чыгып баса. Балалар, җырлый-җырлый, баскан җирдә аяк-кулларын хәрәкәтләндерәләр.

*Наза дигән кыз баланың*

*Бөрлегәне түгелгән.*

*«Наза» дигән уенны без*

*Уйныйбыз чын күңелдән.*

Кушымта:

*Наза, Наза,*

*Наза – матур кыз бала.*

*Наза – тырыш, уңган бала,*

*Зирәк, акыллы бала.*

Кушымталарны җырлаганда, каршыдагы уенчылар арасыннан ялгыз калган бала биеп үтә, үзенә пар сайлый һәм аның белән икенче башка барып баса. Үзе генә калган бала уенны дәвам итә. Уенны башка сүзле җырлар белән дәвам итәргә дә мөмкин.

*Роза, Роза*

*Роза – гөлнең чәчәге.*

*Хәзерге матур тормышның*

*Күңелле киләчәге.*

**8**

**Жырлы – биюле  уен  «Яулык салыш»**

Бу уен күбесенчә кыз балалар тарафыннан уйнала. Кызлар бер урынга түгәрәкләнеп басалар да бер кешене яулык җыючы итеп сайлап куялар. Ул уртага чыгып баса да:

*Талым, талым, талчыбык,*

*Уртасында бал чыбык,*

*Ал яулык, гөл яулык,*

*Бир син миңа бер яулык,*

дип такмаклый-такмаклый, барлык кызлардан да яулык җыеп чыга. Җыеп бетергәч, яулык хуҗаларына берәм-берәм бәза бирелә. Җәзадан соң уен тагын яңадан башлана.

**9**

**Жырлы – биюле  уен «Капкалы»**

Ике бала «капка» ясап (кулларын өскә күтәреп) басалар.

Башка балалар, «Әнисә» көенә (татар халык бию көе) бии-бии,

капка аша узалар. Кинәт кенә капка ябыла (ике бала кулларын

төшерәләр). Капкага эләгүчегә җәза бирелә (шигырь сөйләргә,

мәкаль әйтергә һ. б.).

**10**

**Жырлы – биюле  уен «Кунаклар»**

Уенның сүзләре балалар белән алдан өйрәнелә. Балалар тәгәрәкләнеп басып торалар. Бер бала, кулларын чәбәкли-чәбәкли, җырның беренче куплетын җырлый. Калган балалар аңа җавап кайтаралар – җырның калган өлешен җырлыйлар. Уен барышында төрле хәрәкәтләр ясала. Мәсәлән, өйләре бик тә ямьле» дигәндә, балалар кулларын өскә күтәрәләр, «очтылар, киттеләр» дигәндә, кулларын, як-якка җәеп, очкан кебек итәләр, «башыма килеп кунды» дигәндә, кулларын башларына куялар.

Бала

*Чәбәк, чәбәк, чәптеки –*

*Чәмәк авылы Әптеки.*

*Сез кайларга бардыгыз?*

*Ничек кунак булдыгыз?*

Балалар

*Әбиебезгә бардык без,*

*Кунак булдык, кундык без,*

*Ашатты безгә ашлар,*

*Эчертте ул әйрәннәр.*

*Өйләре бик тә ямьле,*

*Ашлары бик тә тәмле,*

*Әйрәннәре бик татлы,*

*Ә кошлары канатлы –*

*Очтылар, киттеләр,*

*Башыма килеп кундылар!*

*Очтылар, киттеләр,*

*Башыма килеп кундылар!*

**11**

**Җырлы – биюле уен «Куянкай »**

Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәккә басалар. Түгәрәк уртасына баскан бала «куян» була. Ул бер кулын иягенә куеп, моңаеп тора. Түгәрәктәгеләр җырлый-җырлый әйләнәләр: *Ак куянга ни булган,*

*Әллә инде авырган*

*Иптәшен дә табалмый,*

*Урыннан да торалмый,*

*Куян, куян, син сикер,*

*Иптәшең табып китер!*

Куян биленә таянып сикерә башлый. Аннан бер иптәшен уртага алып әйләнәләр дә, чакырылган бала куян булып кала. Уен яңадан башлана.

**12**

**Җырлы – биюле уен «Өч кош»**

Санамыш ярдәмендә өч кош билгеләнә. Калган балалар тәгәрәк ясап басалар да җырлый-җырлый әйләнеп йөриләр. Бу вакытта уртадагы өч кош түгәрәк уртасында утыра. «Берсе очты» дигәндә, берсе очып, түгәрәктән чыгып китә (шулай итеп, икенчесе, өченчесе түгәрәктән чыга). Җыр азагында, кошларга ияреп, барысы да очып таралалар.

*Өч кечкенә кош утыра куакта,*

*Берсе очты-очты еракка…*

*Очты еракка, ул җылы якка,*

*Тик ике кош кына калды куакта.*

*Ике нәни кош утыра куакта,*

*Берсе очты-очты еракка…*

*Очты еракка, ул җылы якка,*

*Бер генә кош калды инде куакта.*

*Бер кечкенә кош утыра куакта,*

*Менә инде ул да очты еракка…*

*Очты еракка, ул җылы якка,*

*Калмады бер кош та инде куакта.*

*Әйдәгез, без дә барыбыз бергә*

*Очыйк кошлар күк, очыйк еракка,*

*Әйдәгез, әйдә, барыбыз бергә*

*Очыйк кошлар күк, җылы якларга-а-а-а-а!.*

**13**

**Жырлы – биюле уен «Коймаклар»**

Балалар кулга-кул тотынышып, түгәрәкләнеп басалар. Уртага бер бала чыга. Кырыйдагы балалар түгәрәк буенча әйләнеп жырлыйлар:

Ямьле бәйрәм көн иде,

Чакырдык без кунаклар.

Кунакларны сыйларга

Салдык майлы коймаклар.

Чыж-чыж итеп коймаклар *(Балалар кулларын як- якка җәяләр)*

Җәелде, әй, җәелде.

Менә тагын кечкенә (*кысылалар)*

Булып калды, (*җыелды)*

Аннан ары кабарды, (*кулларын югары күтәрәләр)*

Кабарды, әй, кабарды.

Шиңде, юп-юка калды. (*чүгәлиләр)*

Пеште инде коймаклар.

Сыйландылар кунаклар,

Тордылар, баш иделәр, (*баш ияләр)*

Таралдылар, әй, шатлар,

Бииләр, әй-әй, шатлар. (бииләр)

**14**

**Жырлы – биюле уен «Нардуган»**

Бер бала уртага чыгарыла. Башка балалар аның тирәсендә бер түгәрәк ясап, кулга-кул тотынышып, шушы нардуган жырын жырлап әйләнәләр. Ул үзенә бер көйгә жырлана.

*Син уртада, без кырыйда,*

*Әйләнәбез, Нардуган,*

*Син нишләсәң, ни кылансаң,*

*Мин дә шуны булдырам!*

Жыр беткәндә, уртадагы бала нинди дә булса бер хәрәкәт ясый, түгәрәктәге балалар да шул хәрәкәтне ясыйлар. Кем шуны булдыра алмый, уртадагы бала үз урынына аны чыгара, һәм уен баштагыча дәвам итә.

**15**

**Жырлы – биюле уен «Түбәтәй»**

Балалар, түгәрәкләнеп басалар. Түбәндәге жырны жырлый- жырлый, түбәтәйне бер-берсенә бирәлђр. Жыр ахырында түбәтәй кемдә булып кала, шуңа җәза бирелә (бии, жырлый, шигырь сөйли, этәч булып кычкыра һ. б.). Уен шулай дәвам итә.

*Түбәтәеңне кигәнсең,*

*Бик ерактан килгәнсең,*

*Төскә матурлыгың белән*

*Шаккатырыйм дигәнсең.*

*Түп-түп-түбәтәй,*

*Түбәтәең укалы.*

*Чиккән матур түбәтәең*

*Менә кемдә тукталды.*

**16**

**Җырлы – биюле уен «Ялкау мәче»**

Бер бала «ялкау мәче» булып, битләрен юып, иснәп, киерлеп утыра. Калган балалар, «тычканнар» булып, урындыкларда утыралар, җырлыйлар. Җыр бетүгә, тычканнар, урыннарыннан торып, төрле якка йөгерешеп китәләр. Мәче тычканнарны куа башлый һәм берсен тота. Тотылган бала «мәче» итеп билгеләнә, уен яңадан башлана. Мич башында мәче

*Утыра, җырлап.*

*Юа битен ул,*

*Иренеп, мырлап.*

*Ул ялкау көндез –*

*Йокыда була.*

*Тора да юына,*

*Киерелеп сузыла.*

*Килсен төн генә –*

*Тычканга каршы*

*Китә ул мәче*

*Сугышырга менә!*

**17**

**Җырлы – биюле уен «Күрсәт әле, Габдулла!»**

Балалар түгәрәк ясап басалар. Бер бала «Габдулла» була. Ул уртага баса. Балалар, җырлап, Габдулладан төрле хәрәкһтләр күрсәтәен сорыйлар. Габдулла балалар сораган хәрәкәтләрне күрсәтә. «Менә шулай, менә шулай», – дип, балалар Габдулла күрсәткән хәрәкәтләрне кабатлап җырлыйлар.

*– Күрсәт әле, Габдулла,*

*Ничек китап укыйлар?*

*– Менә шулай, менә шулай,*

*Шулай китап укыйлар.*

*– Күрсәт әле, Габдулла,*

*Ничек язу язалар?*

*– Менә шулай, менә шулай,*

*Шулай язу язалар.*

*– Күрсәт әле, Габдулла,*

*Ничек печән чабалар? –*

*-Менә шулай, менә шулай,*

*Шулай печән чабалар.*

*– Күрсәт әле, Габдулла,*

*Ничек утын яралар?*

*– Менә шулай, менә шулай,*

*Шулай утын яралар.*

*– Күрсәт әле, Габдулла,*

*Ничек камыр басалар?*

*– Менә шулай, менә шулай,*

*Шулай камыр басалар.*

*– Күрсәт әле, Габдулла,*

*Ничек гармун уйныйлар?*

*– Менә шулай, менә шулай,*

*Шулай гармун уйныйлар…*

**18**

**Җырлы – биюле уен «Габдулла»**

Балалар бер-берсенең кулларына тотынышып, түгәрәкләнеп басалар. Бер бала уртада тора. Түгәрәктәгеләр, җырлый- җырлый, бер якка хәрәкәт итәләр:

*Син уртада, без кырыйда*

*Әйләнәбез, Габдулла.*

*Син нишләсәң, ни кылансаң,*

*Шуны эшләргә була.*

Җыр туктагач, уртадагы бала берәр төрле хәрәкәт ясый, башкалар аның хәрәкәтләрен кабатлыйлар. Әгәр бу хәрәкәтне дөрес ясамаучылар булса, аның берәр әйберен алалар. «Гаепләнүчеләр» саны 3–4 кә җиткәнче, уен шулай кабатлана. Соңыннан аларга берәр төрле җәза бирелә (җырларга, биергә, экият сөйләргә, мәкаль әйтергә һ. б.).

**19**

**Җырлы – биюле уен «Мәк»**

Балалар, ике төркемгә бүленеп, кара-каршы басалар. Бер төркем – «әни», ә икенче төркем «балалар» була. Алар, бер – берләренә сорау-җавап бирү юлы белән, җырның сүзләренә туры китереп, төрле хәрәкәтләр ясыйлар.

*– Әйтсәнә, әнкәем, әйтсәнә, җанкаем,*

*Ничек соң, ничек соң чәчәләр мәк?*

*– Менә шулай, балакаем, менә шулай, гөлкәем,*

*Чәчәләр, чәчәләр, чәчәләр мәк.*

*– Әйтсәнә, әнкәем, әйтсәнә, бәгырем,*

*Ничек соң, ничек соң үсәдер мәк?*

*– Менә шулай, балакаем, менә шулай, күз нурым,*

*Үсәдер, үсәдер, үсәдер мәк.*

*– Әйтсәнә, әнкәем, әйтсәнә, җанкаем,*

*Ничек соң, ничек соң җыялар мәк?*

*– Менә шулай, балакаем, менә шулай, гөлкәем,*

*Җыялар, җыялар, җыялар мәк.*

*– Әйтсәнә, әнкәем, әйтсәнә, бәгырем,*

*Ничек соң, ничек соң пешерәләр мәк?*

*– Менә шулай, балакаем, менә шулай, күз нурым,*

*Пешерәләр, пешерәләр, пешерәләр мәк.*

*– Әйтсәнә, әнкәем, әйтсәнә, җанкаем,*

*Ничек соң, ничек соң ашыйлар мәк?*

*– Менә шулай, балакаем, менә шулай, аппагым,*

*Ашыйлар, ашыйлар, ашыйлар мәк.*

*Уенның 2 нче варианты.* Төркемнәр, бер-берсеннән ераграк басып, җырлый-җырлый, кара-каршы киләләр һәм янә артка чигенәләр. Уен шулай дәвам итә.

**20**

**Җырлы – биюле  уен «Гөл утыртканда»**

Балалар түгәрәкләнеп басалар. Уртада башына кызыл чәчәкләр белән бизәлгән такыя кигән бер бала чүгәләп уты- ра. Аның өстенә карарак төстәге җәймә ябалар. Әлеге бала тирәсендә берничә бала гөл утырткан хәрәкәтләр ясыйлар. Түгәрәктәге барлык башка балалар түбәндәге җырны җырлыйлар:

*Балчык йомшартып*

*Утыртамын гөл,*

*Шытып, яшәреп*

*Чыгар әле ул.*

*Көн саен карап,*

*Мин сибәрмен су,*

*Чәчкә атар ул*

*Кызылсу-алсу.*

*Канатын җәеп, аңа*

*Кунар бер былбыл.*

*Моңланып сайрар:*

*– Син, дип, матур гөл!*

Җыр тәмам булганнан соң,җәймә астыннан «гөл» кәтәрелә. Сандугач киемендәге бер бала түгәрәккә кереп җырлый:

*Ай-яй, матур гөл,*

*Ямьле, ал-кызыл.*

*Сөямен, сиңа*

*Гашыйк мин, былбыл.*

*Җырлар тезәмен*

*Сиңа, ал гөлем,*

*Син үскәндә тик,*

*Ямьле бу илем.*

*Уенга күрсәтмә*

Әлеге уенны, киемнәр киеп, концерт номеры буларак, бәйрәмнәрдә дә башкарырга мөмкин.

**21**

**Жырлы – биюле  уен «Бала белән кош»**

Ике бала кара-каршы җырлыйлар. Берсе – «бала», берсе – «кош».

Бала

*Әй матур кош, азык эзләп*

*Йөрмә әле син салкын көздә.*

*Әзерне ашап, матур читлектә*

*Ят рәхәтләнеп син өебездә.*

Кош

*Юк, юк, дускаем, сәламәт чакта,*

*Әзерне ашап, эшсез ята алмыйм,*

*Матур читлек, рәхәт тормыш өчен*

*Сөйгән ирегемне ташлый алмыйм.*

**22**

**Жырлы – биюле  уен «Бию җыры»**

*Көләбез без, уйныйбыз,*

*Шат күңелле, җырлыйбыз,*

*Без биибез,*

*Безнең яшь чак, шат чак,*

*Шуңа биеп, кул чабабыз чап-чап!*

*Атам-анам биегән,*

*Ямь тапкан ул биюдән,*

*Агам-тутам биегән,*

*Күңел ачкан биюдән.*

*Карап торсын дус-иш,*

*Үрнәк алсын бездән,*

*Без биибез, биибез,*

*Тартынмыйбыз биюдән.*

*Уйнап-җырлап биемәгән –*

*Җебегән ул, җебегән,*

*Уйнап-җырлап биемәгән –*

*Җебегән ул, җебегән!*

**23**

**Жырлы – биюле  уен «Утыр, утыр, Мәликә…»**

Балалар түгәрәккә басалар. Берәү, күзен бәйләп, түгәрәк уртасында утыра. Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәктә жырлап әйләнәләр.

*Утыр, утыр, Мәликә,*

*Алмагачның төбенә,*

*Кем утырган каршыңа –*

*Әйтеп бирче тиз генә!*

Берәү аның янына килеп утыра. Уртадагы бала аны капшап танырга һәм исемен әйтергә тиеш. Әгәр белмәсә, аңа җәза бирелә.

Уен шул рәвешчә дәвам итә.

**24**

**Жырлы – биюле  уен «Тамчы, там!»**

Уенчылар, пар-пар булып, кулга-кул тотынышып, бер-бер

артлы басалар. Алар түбәнәге жырларны бергәләп жырлыйлар һәм бию хәрәкәтләре ясыйлар:

Там, там, тамчы, там, *(Балалар алга баралар)*

Тамганыңны яратам. (*артка таба чигенәләр)*

Тамган тамчыларга карап, (*кара-каршы басып*

Мин жырларга яратам.    *кул чабалар).*

Тамчы тама, тамчы тама,

Тамчы тама түгелме?

Тамчы тамса, матур язлар

Килеп житә түгелме?

Без уйныйбыз, уйныйбыз,

Якты көннән туймыйбыз.

Кулны кулга чаба-чаба

Көләбез дә жырлыйбыз.

Уен шул рәвешчә дәвам итә.

**25**

**Жырлы – биюле  уен «Төймә»**

Балалар, түбәнәге сүзләрне жырлап, түгәрәктә йөриләр һәм, туктап, кушымтасында бииләр.

*Яңгыр ява сибәләп,*

*Төймә-төймә төймәләп.*

Кушымта:

*Их, төймә, төймә, төймә,*

*Төймә була егерме.*

*Бергә жырлыйк, бергә уйныйк,*

*Бергә яшәү күңелле.*

*Җепкә тезгән төймә кебек,*

*Без дә яшик бергәләп.*

Кушымта:

*Их, төймә, төймә, төймә,*

*Төймә була бер җептә.*

*Җепкә тезгән төймәләрнең*

*Матурлыгы берлектә.*

**26**

**Җырлы – биюле уен «Йөзек яшереш»**

Балалар түгәрәккә басып җырлыйлар.

*Сөләйманның йөзеген*

*Дию кызы урлаган.*

*Каф тавының артында*

*Алтын сандыкка салган.*

Көтүче: *Йөзек анда калмаган*

*Аннан песи урлаган.*

*Киң дәрьяны чыкканда*

*Суга төшереп калдырган.*

Күмәк җыр: *Инде йөзек югалган,*

*Табалмассың уңмаган.*

Көтүче: *Киң дәрья туңмаган,*

*Йөзек синдә булмаган!*

дип, берәүнең кулын тота. Әгәр дә йөзек ул баладан чыкса, ул көтүче була. Әгәр дә йөзек ул баладан чыкмаса, баштагы көтүче үз урынында кала.

**27**

**Җырлы – биюле уен «Кәрия – Зәкәрия»**

Балалар кулга – кул тотынышып, түгәрәкләнеп басалар. Уртага бер бала чыга. Түгәрәктәгеләр бер якка хәрәкәт итеп җырлыйлар. Җырларда уртадагы баланың җыр- биюдә, хезмәттә, укуда булган сәләте, уңганлыгы мактала:

*Бу бик яхшы биюче,*

*Бу бик яхшы биюче, }2 тапкыр.*

*Аның биюе матур*

*Аннан үрнәк алыгыз. }2 тапкыр.*

Җырдан соң түгәрәктәгеләр туктап калалар, кул чабып такмак әйтәләр:

*Кәрия, Зәкәрия, коммая,*

*Кәрия, Зәкәрия, коммая.*

*Кәри комма, Зәкәр комма,*

*Зәкәрия, коммая … } 2 тапкыр.*

Бу вакытта уртадагы бала бер иптәшен алып, әйләнеп тора.